РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.12.2025 1065-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 29 гыйнварындагы 116-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - педагогик хезмәткәрләргә - ай саен стимуллаштыра торган өстәмәләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 ноябрендәге №979 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы «Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча билгеләү турында»гы карары нигезендәТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 29 гыйнварындагы 116-п номерлы «Педагогик хезмәткәрләргә-мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә бирү тәртибен раслау турында» гы Саба муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә - педагогик хезмәткәрләргә - ай саен стимуллаштыра торган өстәмәләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 14 пунктның дүртенче абзацында «2 510 сум» сүзләрен «10 000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

**1.2.** 14 пунктның бишенче абзацында «2 510 сум» сүзләрен «10 000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

**1.3.** 15 пунктның дүртенче абзацында « 2 510 сум» сүзләрен «10 000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

**1.4.** 15 пунктның бишенче абзацында « 2 510 сум» сүзләрен «10 000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

**1.5.** 11 пунктта «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары, мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 8 августындагы 678 номерлы карары белән «Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасын, мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларын раслау турында» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 21 февралендәге 225 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга

**2.** Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

**3.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru.рәсми порталында бастырып чыгарырга.

**4.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Ш.А.Сөнгатовка йөкләргә.

Саба муниципаль районының
Башкарма комитет
Җитәкчесе М.Р. Кәримов